| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН СОВЕТ<br>БИК-УТЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БИК- ҮТИ<br>АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | | КАРАР |
| 15 июль 2021ел | | № 1-25 |

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Бик-Үти авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, муниципаль норматив актны законнарга туры китерү максатларында Буа муниципаль районының Бик-Үти авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 февралендәге 61-1 номерлы карары белән расланган (от 12.02.2020 № 79-1, от 20.10.2020 № 1-4, от 23.11.2020 № 1-6, от 22.12.2020 № 1-8, от 22.06.2021 № 4-24 карарлары редакциясендә) (алга таба текст буенча - Нигезләмә),Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Бик-Үти авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 16 Бүлеге:

16.1 пунктының 9 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы (подданствосы) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу турында, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы, муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма чит ил гражданының муниципаль хезмәттә булырга хокукы булган Россия Федерациясе гражданлыгы йә чит ил гражданлыгы (подданствосы) туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яллаучы (эш бирүчегә) вәкиленә язмача хәбәр итәргә;»;

16.1 пунктына 9.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә өстәргә:

«9.1) чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алган яисә яшәүгә рөхсәт кәгазе яисә гражданның чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукынраслый торган башка документ алган очракта, муниципаль хезмәткәргә бу турыда билгеле булган көнне, әмма чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алынган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, яисә чит дәүләт территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документ алган көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, язма рәвештә хәбәр итәргә.;».

16.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Буа муниципаль районының
Бик-Үти авыл җирлеге башлыгы Р.З. Җәләлетдинов